СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

**24.09.2018** пос. Октябрьский **48-210**

Октябрьский авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны кертү һәм гражданнар үзара салым акчаларын файдалану мәсьәләсе буенча билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 28.07.2004 № 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы,Октябрьский авыл җирлеге Уставының 11 статьясы , «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2018 елның 20 сентябрендәге 47-207 номерлы Октябрьский авыл җирлеге Советы карары, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» Октябрьский авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 20 сентябрендәге 114 номерлы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2018 елның 18 ноябренә Октябрьский авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

"2019 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчаларны юллау белән риза булырсызмы:

- Яңа Болгар авылында чишмәне төзекләндерү;
- Матюшино авылында чишмәне төзекләндерү;
- Ключищи авылында, Октябрьский поселогында вак таш җәелгән авыл эчендәге юлларны ямау ремонты

ӘЙЕ ЮК"

3. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль

районының рәсми сайтында, Октябрь авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш.Р. Азизов